Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе
«60 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе»

# Г.Тукай мәкаләләрендә милләт темасының бирелеше

(“Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” “Хиссияте миллия” мәкаләләренә анализ.)

***Башкаручы:***
югары категорияле татар теле
һәм әдәбияты укытучысы
**Попова Гөлниса Гаян кызы**
(өй телефоны 35-44-53)

Яр Чаллы
2018

**Эчтәлек**

**I. Кереш**

**II. 1. Габдулла Тукайның журналист буларак ныгуы һәм танылуы.**

1.1. Җаек – Г. Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны.

1. 2. Революция елларының Г. Тукайның иҗади эшчәнлегендә роле.

**2. “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсенә анализ.**

**3. “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсендә тел-сурәтләү чаралары.**

**III. Йомгаклау**

**IV. Кулланылган әдәбият исемлеге**

## Кереш

*Уртак Ватан тарихында эзле иттең син безне,*

*Мәңге – мәңге тап кунмаслык көзге иттең син безне.*

*Сәнгатебез күкләрендә – кояшыбыз, аебыз,*

*Бар җиһанга күренерлек кадерле Тукаебыз! (И.Юзеев)*

Һәр елны татар халкы түземсезлек белән яз айларын көтеп ала. Ул аны табигатьнең иң матур фасылы булган өчен генә түгел, ә безнең олы шагыйребез Тукай туган, безгә Тукайны бүләк иткән ямьле, матур көннәр итеп тә каршы ала. Чыннан да, татар халкы яшәсә, Тукай яшәр. Тукайны яшәтү өчен татар халкы яшәргә, аның бөеклеген киләчәк гасырларга илтеп җиткерергә тиеш. Тукайны без, хаклы рәвештә, олылыйбыз, зурлыйбыз. Утыз яшенә дә җитмичә якты дөньядан киткән Тукайның иҗатын без гасырдан артык өйрәнәбез, ләкин өйрәнеп бетерә алганыбыз юк әле. Аның иҗаты сусаганда килеп йотлыга-йотлыга эчә торган саф сулы чишмә сыман, эчкән саен эчәсе килеп тора. Гомер буе, авырлык килгәндә дә, шатлык булганда да Тукай әсәрләрен укыйсы килә, күңел шуңа тартыла. Тәнкыйтьчеләр дә аны “мәгърифәтче”, “романтик”, “реалист”, “символист” шагыйрь дип, сәяси яктан, дөньяга карашы ягыннан ул “милләтче”, “социаль-демократ”, олы җәмәгать эшлеклесе, гражданин кебек исемнәр белән атадылар. Алай гына да түгел, ул – поэма белгече, фәлсәфи лирика тарафдары, сатира остасы, журналист, балалар шагыйре, һ.б. Ни генә дисәк тә, Тукай Тукай булып кала. Һәм аның олы, искиткеч бай мирасыннан һәркем үзенә, рухына якынны сайлап ала.

Меңьеллык татар әдәбиятында Тукай – һәр тарафтан уникаль шәхес. Аның шәхес һәм әдәбиятчы буларак үсеше гаҗәеп көчле, тизләтелгән адымнар белән бара. Бу үсешкә Тукай үзен журналистикага бурычлы дип саный. Вакытлы матбугатның җәмгыятьтәге урынын дөрес аңлап, андагы барышка “тәртип” салу рухы белән яши.[1]

[1]Тәлгат Галиуллин. “Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь”, – Казан утлары, 2006 , №4, 59-65 б.

**Фәнни эшнең төп максаты** – “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” “Хиссияте миллия” мәкаләләренә анализ аша Г.Тукай мәкаләләрендә милләт темасының бирелешен өйрәнү.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

– Г.Тукай турында язылган хезмәтләр белән танышып чыгу, аларны өйрәнү, темабызга туры килгән материалларны гомумиләштерү, эшебездә аларга таяну һәм алардан файдалану;

– Г. Тукайның публицистикасының әдәби-эстетик үзенчәлекләрен ачу; публицистикасының телен өйрәнү, аның иҗат елъязмасы белән тулырак, тирәнрәк танышу;

– Тукай иҗаты, шәхесе турында белемнәрне баету.

Сәләтле укучылар белән эшләр өчен, Г.Тукайның мәкаләләренең телен, сурәтләү чараларын җентекләп өйрәнү әһәмиятле дип саныйм. Шуңа күрә Тукай темасына язылган бик күп материалны карап, сөзеп чыгып, үз мөстәкыйль күзәтү-анализларымны бирдем.

Фәнни эзләнү түбәндәге план нигезендә алып барылды:

I. Кереш

II. 1. Габдулла Тукайның журналист буларак ныгуы һәм танылуы.

1.1. Җаек – Г. Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны.

1. 2. Революция елларының Г. Тукайның иҗади эшчәнлегендә роле.

2. “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсенә анализ.

3. “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсенең тел-сурәтләү чаралары.

III. Йомгаклау

IV. Кулланылган әдәбият исемлеге

**II. 1. Габдулла Тукайның журналист буларак ныгуы һәм танылуы.**

**1.1. Җаек – Г.Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны.**

1894 – 1895 еллар арасындагы кышта Габдулланы әтисенең сеңлесе Газизә апасы белән Галиәсгар җизнәсе Җаекка алып китәләр. Берничә елдан, җизнәсе үлгәч, ундүрт яшьлек малай торырга «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә күчә, ягъни үз көнен тулысынча үзе күрә башлый. Ул Җаекта унике ел яши. Шунда егет булып җитешә, шагыйрь буларак танылa.

Тормышының бу вакытында аңа Мотыйгулла хәзрәт матди һәм рухи ярдәм итүче булып әверелә. Үзенең яшьлек дустының малаен ул бик якын итә, йортына ияләштерергә, ашау-эчү якларын, кием-салымын кайгыртырга тырыша. Улы Камил язганча, Мотыйгулла хәзрәт «ул вакытта Уральскида имам вә ахун булып торганга күрә, кулындагы русча язылa торган бөтен хезмәтләрене диярлек Габдуллага кушып, шул хезмәтләре өчен аңарга мәдрәсәдә бер дә ихтыяҗ күрмәслек дәрәҗәдә акчалар бирә иде».

Габдуллага шигырь иҗат итү серләрен беренче булып өйрәтүче дә – Мотыйгулла хәзрәт. Ул төрле яклап галим кеше, борынгы Көнчыгыш фәлсәфәсе һәм шигърияте, астрономия буенча да тирән мәгълүматлы, зыялы кеше була. Алар еш кына төрле өлкәләр буенча озак-озак сөйләшеп утыралар. Улы Камил исеменә сатып алган типографиядә дә Габдулла төп хезмәтләрне башкара. К. Мотыйгый болай яза: «Мин шул елны (1905 ел. –Ф. Г.) 27 ноябрьдән башлап «Фикер» исемле газета чыгара башлагач, аны шул газетага мөсәххих итеп куйдым. Габдулла әфәнденең хезмәте миңа бик ягымлы һәм үзе дә фәүкыльгадә иҗтиһатлы булганга күрә, мин аның жалуниясен һәр ай саен арттыра бара идем. «Фикер» газетасының иң әүвәлге номерында аның «Ник йоклыйсың, мужик?» исемле шигыре басылып чыкты. 1906 ел башында, мин «Әлгасрел-җәдит» журналы чыгара башладым. Аның да иң әүвәлге номерында Габдулла Тукаевның «Алла гыйшкына» исемле шигыре басылды. Мәзкүр ел ахырында «Уклар» нам һөҗү журнал чыгара башладык. Аңарга да Габдулла Тукаев күп шигырьләр чыгарып бастырды.

Шулай итә-итә акрынлап Габдулла Тукаев минем матбугамда иң әүвәл наборщик булып кергән дәрәҗәсеннән... соңра бик тизлек илә... газета-журналлар-ның иң моктадир шагыйрь вә мөхәррире дәрәҗәләренә ирешеп, бөтен эшне үз кулына алырга якынлашты».

Шагыйрь, язучы булып үсү өчен, талантың булу өстенә, язган әйберләреңне бастыру мөмкинлеге дә кирәк. Күргәнебезчә, Төхфәтуллиннар гаиләсе (аталы-уллы Мотыйгулла белән Камил) Габдуллага үзләренең газета-журналларында әнә нинди уңайлы шартлар тудыралар.

Димәк, ни генә әйтсәк тә, Җаек – Г. Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны. Җаек шагыйре Габдулла Тукайны инде Казанда, Оренбургта, Уфада яхшы беләләр. Беренче адымнан ук шагыйрь үзенең урыны хаклык, халык мәнфәгатьләре өчен көрәш һәм дөреслекне чагылдыру булырга тиеш, дигән караштa тора. Журналист буларак, 1905 елның ноябрендә Жаекта чыга башлаган “Фикер” газетасының беренче санында ук Тукай үзенең әсәрләрен бастыра. “Әлгасрел-җәдит” һәм “Уклар” кебек журналларда күпләгән шигырь, мәкалә һәм фельетоннар белән чыгыш ясый. “Уклар” журналы татар телендәге беренче сатирик басма булып, башыннан азагына кадәр Тукай редакциясендә чыгарыла.

**1.2. Революция елларының Г. Тукайның иҗади эшчәнлегендә роле.**

Г.Тукай туган ягына ашкына һәм 1907 елның көзендә Җаектан Казанга күчеп килә. Туган ягына ул өлгергән журналист, канатлары ныгыган шагыйрь, ачы телле сатирик, сәяси көрәшче, һәм публицист булып кайта. Дәртләнеп, җиң сызганып иҗат эшенә керешә. Әдәбият язмышы, аның үсешен кайгырта. Казанга килүгә, Ф.Әмирхан җитәкләгән “Әл-ислах”газетасы эшендә актив катнаша башлый. 1908 елда Г.Камал белән бергә сатирик “Яшен” журналын чыгаруга ирешә. Аның беренче санында “Август башы” мәкаләсе белән чыгыш ясап, үзенең тоткан юлын, иҗат программасын күрсәтә. 1908-1909 елларда, замана алып килгән вәзгыятьтән вакытлы матбугат (хәзер аның күз уңында күбрәк сатирик журналлар) низагъларыннан читләшмәсә дә, Тукай иҗатының үзәгенә милли мәсьәләләр

килеп керә, татар халкының яшәеше, киләчәге, теле, мәгърифәте аның бәгырен телгәли, иҗатының, төп юнәлешен миллилек, милли идея, татарлык билгели. Милләт яшәеше өчен көрәш идеясе аның һәр әсәрендә диярлек ярылып ята. Биредә Тукай характерының шактый кырыс булуын һәм эчке мөстәкыйльлекне югары бәяләвен онытырга ярамый.

1910 елның башында журналист Әхмәт Урманчиев мөхәррирлегендә сатирак журнал “Ялт-йолт” чыга башлый. Бу журналда эшләп, Г.Тукай татар ирекле матбугатның традицияләрен дәвам иттерә, үзенең кыю әсәрләре белән замананың иң әһәмиятле сорауларына җавап һәм бәя бирә.

Димәк, революция еллары яшь шагыйрьнең аңын тиз үстерә. Аның иҗатында күтәрелгән мотивлар арасында татар халкын күп гасырлар буена басып торган иске, реакцион көчләргә һәм гадәтләргә каршы һөҗүмгә чакыру идеясе ачык чагыла. Шушы мотивларда шагыйрьнең милли азатлык һәм мәгърифәтлек хәрәкәте белән бәйле теләкләре алга чыга. Йомгаклап әйткәндә, Казанга кайту Г. Тукай өчен халкыбыз теленә кайту да булган икән. “Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!”, “Без татарлар һаман да татарлар булып калдык”,— дип язды Г.Тукай, горурланып. Бу сүзләрдә тирән мәгънә бар. Әйе, башка халыкларның әдәбиятларына сокланырга, алардагы үз күңелеңә аваздаш якларга битараф булмаска мөмкин, әмма синең әдәбиятыңны да башкалар үз итсеннәр дисәң, аны нигездә туган милләтеңнең сәнгатьчә фикерләү чаралары ярдәмендә үстерү зарур. Моны гамәлгә ашыруы – Г.Тукайның әдәбиятыбыз алдында күрсәткән тагын бер зур хезмәте. Халык рухы шагыйрь әсәрләренең тукымасында бик табигый урын алды.

## 2. “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсенә анализ.

1906 елларда Г.Тукай сатирага мөрәҗәгать итә башлый һәм “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсендә яңалыкка каршы торучыларга кискен ут ача. Әсәр публицистик стильдә басылган. Темасы – иҗтимагый-политик. Язучы милләткә битараф түгел, аның өчен җан көеп тә, үпкәләп тә, ачуланып та яза. Әсәр башында ук ул, Тукайча, бөтереп алып

кереп китә дә, сулыш алырга да ирек бирмичә, йомгаклап та куя. Милләт дөнья көпчәгенең дөбердәвенә дә, башка милләтләрнең йөрәк яргыч тавышларына да уянмый, ди ул. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр бер риторик сорау: безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Тукай милләтне агартырга, үзгәртергә теләп газета-журналлар чыгарырга тырышып йөрүчеләргә дә “саллы гына” итеп: “безнең гәзитәләр... ясин шәрәф укуга гына охшап калмасмы?” дип әйтә. Менә нәрсә борчый яшь Габдулланы. Күпме хезмәт, борчулы төннәр милләт күңелендә “шыта алырмы?” Башка милләтләр дә “чәйдәш” булганнар. Ләкин алар һәрберсе Сөләйман мөлкен алып, “үзләренә җилләрне, парларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр”.

Габдулла Тукай милләтне күтәрү юлларын байларны талауда, адәмне адәмгә каршы көрәштерүдә түгел, ә әдәбиятны, сәнгатьне үстерүдә, берләштерүдә күрә. Никадәр милләтен яратуын, сабый баланы иркәләгән, кадерләгән кебек сөйләвендә күрәбез: “әдәбият гөл сулары сибик”, “газета мәрвәхәләре илә йомшак җил истерик”, “җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик”, “милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик”. Милләтне “бичара”, “мескен” дип кызганса да, курыкмыйча эшкә тотынсак, “синең бабаларың булган Бәгъдад вә Әндәләс” халыклар кебек үсеш булыр дип өнди. Ләкин, Тукай фикеренчә, милләтнең “кабыргасын тишкән... Бохара козгыннарын” кусак, “көзгедән канлы авызларын” күрсәтсәк, милләт алга китәр, дигән өмет белән яши. Әсәрен Г.Тукай: “һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем – милләт үзе аерыр”, – дип йомгаклый.

**3. “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсенең тел-сурәтләү чаралары.**

Әйтеп киткәнчә, татар милләтенең проблемалары – Г.Тукайның төп тематикасы. Татар хезмәт ияләре арасында халык мәгарифен таратуда, яңа тип мәктәпләр булдыру өчен көрәштә, татарлар арасында педагогик фикерне үстерүдә, туган телебездә төрле дәреслекләр һәм уку китаплары төзүдә Г.Тукайның хезмәтләре гаҗәеп зур. Ул милли проблеманың чишелешен халык мәнфәгатьләре өчен көрәшүче мәшһүр җәмәгать эшлеклеләре

булырлык кешеләр тәрбияләү бурычын алга куйды. “Безнең милләт тә, – дип язды Г.Тукай 1906 елда “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсендә, – башка милләтләрдәге кебек, яклаучысы, сыена торган урыны булмаган, фәкыйрь вә эшче халыкның файдасына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алыштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ”. Әсәрдә укыту-белем бирү проблемасы күтәрелә. Жанры – сатирик тасфирлы мәкалә, түбәнәйтелгән стильдә язылган. Автор “укытучы битлеген киеп, култык астына китаплар кыстырган булып, 25 җирдән ( **гипербола**) аш ашагач, абыстай янына корсагын (**жаргон сүзе**) күтәреп кайтып җитү авыр булганлыктан, гына мәдрәсәгә туктап (... ), бераз хәл җыйгач чыгып китә торган мөдәррисләр кул астыннан һәмишә чыкмагандыр” дип, әсәр башында ук кисәтеп куя. Әсәрнең теле бай һәм “ачы”. **Фразиологик бөтеннәр**: “чыга алмаслык  наданлык урманына кертеп адаштыру”, “гыйлемнән максудлары бер такым сыра мичкәсе булган”, “иң түбән теләнчедән дә түбән” , “биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакыт” , “теләнче фабрикасы”, “гимназия казаннарына кереп пешеп, кеше булып чыгарга”, “итәкләренәябышып”, “мендәр өстендә корсак шиңдереп утыру”, “гыйлемнең алдына тез чүгеп”; **фразиологик ныгыма**: “баш катырып”;  **чагыштырулар:** “үлек чыккан өй төсле моңлы”, “ җәйге кояшсыз мәңгелек көз төсле” авторның теле никадәр бай икәнлеген күрсәтә. Г.Тукай бу мәкаләсендә **анафорага** нигезләнеп фикерен тагын да үтемлерәк итә :

1. “*Милләт* образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигын вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт арысланнарына *мохтаҗ*. *Милләт* аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә, чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә (**синонимнар**) *мохтаҗ*. *Безнең милләт* тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, (...) аңлаучы вә аңлатучы егетләргә *мохтаҗ*. *Безнең милләт* тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга *мохтаҗ*. Кыскасы гына, *безнең милләт* тә башка милләтләрнең тәрәкъкыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә,

рәссамнәргә, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә *мохтаҗ.*

2. *Укымак* – дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә (**антонимнар)** иң үткен, иң кирәкле коралдыр. *Укымак* – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. *Укымак* – үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. *Укымак* – үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр – истикъбальләр тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. *Укымак* – хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү угърында ташламак димәктер. *Укымак* – бүгенге дустлардан киләчәктәге кара көннәр өчен аерылмак димәктер. *Укымак* – үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. *Укымак* – "иҗтиһад мөнкариз" кеби сүзләрдән ха-ха-ха илә көлеп, гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагында чынлап кайрамак дигән сүздер (**фигыльләргә билгесезлек кисәкчәсе ялганган).** *Укымак* – утыз ел мәдрәсәдә ятып, бер татар баеның эштән чыккан кызы илә бер аулак бүлмәгә кереп яту, соңра шул байның бер асрау малае булып тору дигән сүз түгелдер. (укымак сүзе шулай ук кабатланса да, автор "уттан алып суга салу" максатыннан **түгел модаль сүзен кулланып**, каршылык тудыра, ягъни кире образны күрсәтү аша яшьләргә акыл бирә). *"Укымак"* – ләфзы (автор, **куштырнаклар эченә алып**, кабатланып килүче сүзгә өстәмә мәгънә бирә) астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр. *Укымак* – халыкның бәлешен ашап, канын эчеп, үзеңне симертеп, ел саен бер бай кызы үтереп яки аерып, хайванлык итеп яту дигән сүз түгелдер".

Мәкаләсен автор өндәү белән йомгаклый: "Тырышыңыз, карендәшләр шәкертләр, тырышыңыз! Муллаларның мендәр өстендә корсак шиңдереп утыруларына канәгать итмәгез. Бөтен өмидегез, бөтен риҗаэ вә илтимасымыз анчак сезгә гаиддер (Үтенеч һәм сорауларыбыз бары тик сезгә генә юнәлгән)".

**III. Йомгаклау.**

*Минем буын язучыларга Тукай, билгеле, якынрак тора. Без туганда Тукай үзе дә исән булган әле. Өч яшьтән үк без аны белеп, укып үстек. Тукай белән телебез ачылды, дөньяга күзебез дә ачылды. Безнең рухи дөньябызга иң тирән эзне салучы да Тукай булды. Әлбәттә, Тукайның чын мәгънәсендәге кешелекле, халыкчан, демократик иҗаты бүгенге буынны һәм киләчәктәге бик күп буыннарны да рухи тәрбияләп, баетып торачак. Тукай мирасы тирән диңгезне хәтерләтә. Аның төбендә яткан шигъри һәм мәгънәви гәүһәрләрне эзләү, табу дәвам итәчәк. Бу урында бөек шагыйрьнең бер бик мөһим сыйфатына тукталасым килә. Тукай үз халкының үткәнен бик яхшы белгән һәм исендә тоткан. Тукай үз халкының хәзерге, ягъни үзе яшәгән чордагы тормышны гаять тирән аңлаган. Ниһаять, Тукай үз халкының киләчәге турында даими уйланып, кайгыртып яшәгән. Миңа калса, һәр заманда да чын язучыларга Тукаебызның нәә шул сыйфаты, ягъни үз халкыңның үткәнен белү, бүгенгесен аңлау, киләчәген кайгырту хас булырга тиеш. (Әмирхан Еники, Татарстанның халык язучысы).*

Тукай нибары 27 ел яшәде, әмма үтеп чыга алмаслык эш башкарырга өлгерде. Күрәсең, аз гомер яшәп тә, зур эшләр башкарырга, халык күңеленә мәңгелеккә кереп калырга мөмкин икән. Тукай – шундыйларның берсе. Ул: “Халкым өчен яшәдем”, - дип әйтергә хаклы. Чөнки 1908 елдан алып, соңгы сулышына кадәр Тукай милләт хәсрәтен, халык язмышын уйлаган. Сигез ел буе ару-талуны белмәгән каләме 1913 елның апрелендә туктап калды. Ләкин аның әдәби мирасы мәңгелек. Габдулла Тукайның иҗаты – татар халкының йөз аклыгы ул. Мондый шагыйре, үзенчәлекле шәхесе булган милләт – зур һәм талантлы милләт, үткәне һәм бигрәк тә киләчәге булган милләт.

**Фәнни эшнең төп максаты** – “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” “Хиссияте миллия” мәкаләләренә анализ аша Г.Тукай мәкаләләрендә милләт темасының бирелешен өйрәнү иде.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

– Г.Тукай турында язылган хезмәтләр белән танышып чыгу, аларны өйрәнү, темабызга туры килгән материалларны гомумиләштерү, эшебездә аларга таяну һәм алардан файдалану;

– Г. Тукайның публицистикасының әдәби-эстетик үзенчәлекләрен ачу; публицистикасының телен өйрәнү, аның иҗат елъязмасы белән тулырак, тирәнрәк танышу;

– Тукай иҗаты, шәхесе турында белемнәрне баету.

Сәләтле укучылар белән эшләр өчен, Г.Тукайның мәкаләләренең телен, сурәтләү чараларын җентекләп өйрәнү әһәмиятле дип саныйм. Шуңа күрә Тукай темасына язылган бик күп материалны карап, сөзеп чыгып, үз мөстәкыйль күзәтү-анализларымны бирдем.

Фәнни эзләнү түбәндәге план нигезендә алып барылды:

**I. Кереш өлешендә** без меңьеллык татар әдәбиятында Г.Тукайның һәр тарафтан уникаль шәхес булуын һәм тәнкыйтьчеләрнең дә аны “мәгърифәтче”, “романтик”, “реалист”, “символист” шагыйрь дип, сәяси яктан, дөньяга карашы ягыннан ул “милләтче”, “социаль-демократ”, олы җәмәгать эшлеклесе, гражданин кебек исемнәр белән атауларын әйтеп үттек. Алай гына да түгел, аның – поэма белгече, фәлсәфи лирика тарафдары, сатира остасы, журналист, балалар шагыйре булуына да басым ясадык.

Төп өлеш берничә темага бүлеп өйрәнелде.

**1. Габдулла Тукайның журналист буларак ныгуы һәм танылуы.**

**1.1. Җаек – Г. Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны.** Җаек шагыйре Габдулла Тукайны инде Казанда, Оренбургта, Уфада яхшы беләләр. Беренче адымнан ук шагыйрь үзенең урыны хаклык, халык мәнфәгатьләре өчен көрәш һәм дөреслекне чагылдыру булырга тиеш, дигән караштa тора. Журналист буларак, 1905 елның ноябрендә Жаекта чыга башлаган “Фикер” газетасының беренче санында ук Тукай үзенең әсәрләрен бастыра. “Әлгасрел-җәдит” һәм “Уклар” кебек журналларда күпләгән шигырь, мәкалә һәм фельетоннар белән чыгыш ясый.

“Уклар” журналы татар телендәге беренче сатирик басма булып, башыннан азагына кадәр Тукай редакциясендә чыгарыла.

**1. 2. Революция елларының Г. Тукайның иҗади эшчәнлегендә роле.** Революция еллары яшь шагыйрьнең аңын тиз үстерә. Аның иҗатында күтәрелгән мотивлар арасында татар халкын күп гасырлар буена басып торган иске, реакцион көчләргә һәм гадәтләргә каршы һөҗүмгә чакыру идеясе ачык чагыла. Шушы мотивларда шагыйрьнең милли азатлык һәм мәгърифәтлек хәрәкәте белән бәйле теләкләре алга чыга.

**2. “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсенә анализ.** 1906 елларда Г.Тукай сатирага мөрәҗәгать итә башлый һәм “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” мәкаләсендә яңалыкка каршы торучыларга кискен ут ача. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр бер риторик сорау: безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Тукай милләтне агартырга, үзгәртергә теләп газета-журналлар чыгарырга тырышып йөрүчеләргә дә “саллы гына” итеп: “безнең гәзитәләр... ясин шәрәф укуга гына охшап калмасмы?” дип әйтә. Ләкин, Тукай фикеренчә, милләтнең “кабыргасын тишкән... Бохара козгыннарын” кусак, “көзгедән канлы авызларын” күрсәтсәк, милләт алга китәр, дигән өмет белән яши. Әсәрен Г.Тукай: “һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем – милләт үзе аерыр”, – дип йомгаклый.

**3. “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсенең тел-сурәтләү чаралары.** Әйтеп киткәнчә, татар милләтенең проблемалары – аның төп тематикасы. Г.Тукай 1906 елда “Хиссияте миллия” дигән мәкаләсендә, – башка милләтләрдәге кебек, яклаучысы, сыена торган урыны булмаган, фәкыйрь вә эшче халыкның файдасына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алыштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ”. Әсәрдә укыту-белем бирү проблемасы күтәрелә. Жанры – сатирик тасфирлы мәкалә, түбәнәйтелгән стильдә язылган.

Мәкаләсен автор өндәү белән йомгаклый: “Тырышыңыз, карендәшләр шәкертләр, тырышыңыз! Муллаларның мендәр өстендә корсак шиңдереп

утыруларына канәгать итмәгез. Бөтен өмидегез, бөтен риҗаэ вә илтимасымыз анчак сезгә гаиддер (Үтенеч һәм сорауларыбыз бары тик сезгә генә юнәлгән)".

Г. Тукай шагыйрь генә түгел, бәлки халкыбызның теле дә, моңы да, рухы да, язмышы да. Ул чын мәгънәсендә халыкның үз улы, шуңа күрә аның хасиятләрен, мәнфәгатьләрен тирән белүче һәм шуларны сәнгатьлелекнең иң югары кимәлендә сурәтләп бирүче иде.

**Кулланылган әдәбият исемлеге.**

1. Әдһәмова Г.М., Сафиуллина Ф.С.,Фатыйхова Ф.Ф., Юзиев Н. Г. Татар Совет әдәбияты һәм туган тел. – Казан: ТКН, 1991. – 187 - 193 б.

2. Габдулла Тукай. Әсәрләр 5 томда, – Казан: ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова, 1985.

3. Вәлиев М. Х. Табарга һәм югалтмаска. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: ТКН, 1982.

4. Гыйззәтуллин Н. Әдәбият һәм тормыш. (Әдәби тәнкыйть мәкаләләре). – Казан: ТКН, 1982. – 3 – 22 б.

5. Тәлгат Галиуллин. "Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь", – Казан утлары, 2006 , №4, 59-65 б.

6. Үзбәк Гыймадиев. Тукай мирасы турында "Ялт- йолт". –Казан утлары, 1978, №6, 154-158 б.

7. Даутов Р., Исмагыйль Рәми. Әдәби сүзлек. ( Элекке татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: ТКН, 2001. – 399 б.

8.Заһидуллина Д.Ф.,Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. (Теория. Тарих.) – Казан: Мәгариф нәшрияты, 2004. – 247 б.

9. Курбатов Х. Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: ТКН, 1971. – 196 б.

10. Мансур Вәли – Барҗылы. Күңелем кошы. (Укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма). – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2004.

11. Мусин Ф.М.,Зәкиев М.З., Хәсәнов М.Х., Асылгәрәева Ш.Н. Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте (Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыгара конференция материаллары) – Казан: ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова, 1997.

12. Нуруллин И.З. Габдулла Тукай. – Казан: ТКН, 1979.

13. Сәхапов М. Хакыйкать йөзе.– Казан: "Мәгариф" нәшрияты. 2005. – 319 б.

14. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. (Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма). – Казан: "Мәгариф" нәшрияты. 2000.